**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында

Урман мөнәсәбәтләрен җайга салучы норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Кушымтада бирелгән исемлек нигезендә Татарстан Республикасы Президенты указларына үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 11 гыйнвар
№ ПУ-4

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның « 11 » гыйнварындагы
ПУ- 4 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Аукцион нәтиҗәләре буенча урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлеген арендага бирү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2011 елның 11 ноябрендәге ПУ-716 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 24 декабрендәге ПУ-862 номерлы, 2012 елның 18 июнендәге ПУ-478 номерлы, 2013 елның 12 октябрендәге ПУ-1012 номерлы, 2016 елның 15 гыйнварындагы ПУ-6 номерлы һәм 2016 елның 8 октябрендәге ПУ-911 номерлы һәм 2017 елның 27 июлендәге ПУ-660 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Аукцион нәтиҗәләре буенча урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлеген арендага бирү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.2 пунктта «аренда шартнамәсен төзүгә хокук сату буенча» сүзләрен «аренда шартнамәсен төзү хокукына» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан күрсәтелә.

Министрлык, аның дәүләт хезмәтен күрсәтүче структур бүлекчәсе турында белешмә мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (http://minleshoz.tatarstan.ru/), «Дәүләт хезмәтләренең (функцияләренең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.gosuslugi.ru), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) урнаштырыла.»;

1.4, 1.5 пунктларны һәм 1.6 пунктның 1 пунктчасы көчен югалткан дип танырга;

1.6 пунктның 3 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«сатулар уздыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясе рәсми сайтында (http://torgi.gov.ru) (алга таба – сатуларның рәсми сайты);»;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең гомуми срогы – кимендә 57 көн.

Аукцион уздыру турында карар кабул итү көненнән кимендә 30 көннән соң һәм аукцион уздыру көненә кадәр кимендә 35 көн алдан сатуларның рәсми сайтында Министрлыкның аренда мөнәсәбәтләре бүлеге белгече тарафыннан аукцион уздыру турында хәбәр урнаштырыла.

Аукционда катнашуга гариза тапшыру срогы кимендә 30 көн тәшкил итә.

Гариза кабул ителгән көннән башлап ике көннән дә артык булмаган вакыт дәвамында алдан түләү өлеше турында килешү төзелә.

Аукционда катнашуга гаризалар тапшыру срогы тәмамланган көннән соң бер көннән дә артык булмаган вакыт дәвамында аукционда катнашуга гаризалар кабул итү беркетмәсенә имза куела.

Аукционда катнашуга гаризалар кабул итү беркетмәсенә имза куелган көннән соң бер көннән дә артык булмаган вакыт дәвамында аукционда катнашуга кертелгән гариза итүчеләргә һәм аукционда катнашуга кертелмәгән гариза итүчеләргә кабул ителгән карар турында хәбәр ителә;.

Аукционда катнашуга гаризалар кабул итү беркетмәсенә имза куелган көннән башлап биш көннән дә артык булмаган вакыт дәвамында аукционда катнашуга кертелмәгән затларга алдан түләү өлешен кайтарып бирү гамәлгә ашырыла.

Бер көн дәвамында аукцион уздырыла һәм аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәгә кул куела.

Аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә имзаланган көннән өч эш көне дәвамында аукционда җиңүчегә, аукциондагы калган катнашучыларга беркетмә җибәрелә.

Аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә имзаланган көннән бер көн дәвамында аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүмат сатуларның рәсми сайтында урнаштырыла.

Аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүмат сатуларның рәсми сайтында урнаштырылган көннән 10 көн узганнан соң аукционда җиңүче белән дәүләт мөлкәтендә торучы урман кишәрлегенең (алга таба шулай ук – урман кишәрлеге) аренда шартнамәсе төзелә.

Аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүмат сатуларның рәсми сайтында урнаштырылган көннән 20 көннән дә соңга калмыйча, аукционда катнашу өчен бердәндер гариза тапшырган гариза бирүче белән яки аукционда бердәнбер катнашучы белән урман кишәрлеген арендага алу шартнамәсе төзелә.

Аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәгә (аукционны узмаган дип тану турында беркетмәгә) кул куелган көннән биш эш көненнән дә артык булмаган вакыт дәвамында аукционда җиңүче булмаган катнашучыларга алдан түләү өлеше кайтарып бирелә.»;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (http://minleshoz.tatarstan.ru), «Дәүләт

хезмәтләренең (функцияләренең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.gosuslugi.ru), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) урнаштырыла торган норматив хокукый актлар нигезендә җайга салына.»;

2.6 пунктта:

1 пунктчада «аренда шартнамәсен төзүгә хокук сату буенча» сүзләрен «аренда шартнамәсен төзү хокукына» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхсән гариза иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлеп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:

шәхсән (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);

почта юлламасы белән.»;

2.6[1] пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.6 пунктында билгеләнде.»;

2.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү яисә 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 өлеше 4 пункты нигезендә билгеләнгән очраклардан кала, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларның булмавы һәм (яисә) аларда күрсәтелгән мәгълүматның дөрес булмавы беренче тапкыр документларны кабул итүдән баш тартуда күрсәтелмәгән документлар һәм белешмәләрне бирү.»;

2.9 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) аңа карата банкротлык турында эш алып бару процедуралары уздырылган затның аукционда катнашуга гариза бирүе;»;

2 пунктчада «гариза бирүче – граждан тарафыннан туктатылу» сүзләрен «гариза бирүче – граждан тарафыннан туктату турында карар кабул итү»;

3 пунктчада «соң» сүзен «кадәр» сүзенә алмаштырырга;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе Урман кодексының 78 статьясының 6 өлеше һәм 80[1] статьясының 8 өлеше нигезендә Министрлыкның сатулар уздырудан баш тартуы;»;

түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) гариза бирүченең намуссыз рәвештә урман кишәрлекләрен арендага алучылар һәм урман утыртмаларын сатып алучылар реестрында

булуы.»;

2.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.17. Гариза бирүче дәүләт хезмәтен алуга гариза белән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәккә (алга таба – күпфункцияле үзәк) гариза итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәктән дәүләт хезмәте алуга гариза килгәндә, процедуралар әлеге Административ регламент нигезендә гамәлгә ашырыла.

Күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтелми.»;

2.18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.18. Дәүләт хезмәте электрон рәвештә күрсәтелми.»;

3.1 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сатуларда бердәнбер катнашучы (аукционда катнашу өчен бердәнбер гариза тапшырган гариза итүче) белән шартнамә төзү.»;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Аукцион уздыру турында карар кабул итү көненнән кимендә 30 көннән соң һәм аукцион уздыру көненә кадәр кимендә 35 көн алдан сатуларның рәсми сайтында Министрлыкның аренда мөнәсәбәтләре бүлеге белгече тарафыннан аукцион уздыру турында хәбәр урнаштырыла.»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Сатулар уздыру турында хәбәрдә түбәндәге белешмәләр була:

1) аукцион оештыручы – Министрлык турында;

2) аукцион уздыру турында карар реквизитлары хакында;

3) аукционның предметы турында;

4) сату өчен күздә тотылган урман утыртмалары турында яисә арендага тапшыру өчен күздә тотылган, дәүләт мөлкәтендә торучы урман кишәрлеге (шул исәптән урман кишәрлегенең урнашкан урыны, мәйданы һәм кадастр номеры, урман кишәрлегенә булган хокуклар турында, әлеге хокукларда чикләүләр турында) һәм әзерләнергә тиешле урман ресурслары турында;

5) урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре һәм параметрлары турында;

6) аукцион уздыру урыны, датасы һәм вакыты турында;

7) аукцион предметының башлангыч бәясе турында;

8) аукцион предметының башлангыч бәясен арттыру зурлыгы («аукцион адымы») турында, аның күләме аукцион предметының башлангыч бәясенең биш процентыннан артык була алмый;

9) аукционда катнашуга гариза формасы, аны кабул итү тәртибе турында, аны кабул итү урынының адресы турында, аукционда катнашуга гаризаларны кабул итә башлау һәм тәмамлау датасы һәм вакыты турында;

10) алдан түләү өлешенең күләме, аны аукционда катнашучылар тарафыннан кертү һәм аларга алдан түләү өлешен кайтарып бирү тәртибе, алдан түләү өлешен күчерү өчен банк реквизитлары турында;

11) дәүләт мөлкәтендә торучы урман кишәрлегенең аренда срогы турында;

12) аукцион нәтиҗәләре буенча дәүләт милкәтендә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе төзелергә тиешле срок турында.»;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Сатуларның рәсми сайтында сатулар уздыру турында хәбәр урнаштыру белән бер үк вакытта сатулар турында документлар да урнаштырыла, аларда, сатулар турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән белешмәләрдән тыш, түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) урман кишәрлегенең проект документлары;

2) арендага тапшыру өчен күздә тотылган урман кишәрлегенә карата Күчемсез милкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

3) урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе проекты;

4) сатуларда катнашу өчен гариза формасы, шулай ук аны тутыру буенча инструкция.»;

3.13 пунктта «10» санын «50» санына алмаштырырга;

3.33 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.33. Аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә аукционны оештыру тарафыннан аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәгә кул куелган көннән бер көн дәвамында сатуларның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

Аукционны оештыручы аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәгә кул куелган көннән өч эш көне дәвамында күрсәтелгән беркетмәне аукционда җиңүчегә, аукциондагы башка катнашучыларга җибәрә.»;

3.35 һәм 3.36 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.35. Аукцион узмаган дип таныла, әгәр:

1) аукционда катнашу өчен бер генә гариза да тапшырылмаса;

2) аукционда катнашу өчен бер генә гариза тапшырылса;

3) аукционда катнашучыларның икедән киме аукционда катнашса;

4) аукцион предметының башлангыч бәясе өч мәртәбә игълан ителгәннән соң аукционда катнашучыларның берсе дә үзенең дәүләт милкәтендә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен аукцион предметының башлангыч бәясеннән төзү нияте турында белдермәсә.

3.36. Процедураның нәтиҗәсе булып аукционда җиңүчене ачыклау яисә аукционны узмаган дип тану тора.»;

III бүлектә «Аукционны уздыру һәм җиңүчене билгеләү (аукционны узмаган дип тану) бүлекчәсеннән соң түбәндәге эчтәлекле «Аукционны электрон рәвештә уздыру» бүлекчәсен өстәргә:

«Аукционны электрон рәвештә уздыру

3.37. Аукционны электрон рәвештә уздыру турында мәгълүмат аукционны оештыру тарафыннан сатуларның рәсми сайтында урнаштырылу белән бер үк вакытта электрон рәвештә сатулар уздыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтта (алга таба – электрон мәйданчык) урнаштырылырга тиеш.

3.38. Аукционны электрон рәвештә уздыру турында хәбәрнамә әлеге Административ регламентның 3.6 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлардан тыш түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) аукционны электрон рәвештә уздыру турында күрсәтмә;

2) аукцион турында документация урнаштырылган электрон мәйданчык турында мәгълүмат.

3.39. Аукционны электрон рәвештә уздыру дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә функцияләүче электрон мәйданчыкларның операторлары арасыннан электрон оператор тарафыннан тәэмин ителә.

3.40. Аукцион уздырылган көнне электрон рәвештә уздырылган аукцион нәтиҗәләре буенча төзелә торган беркетмә электрон документ рәвешендә әзерләнә, ул аукционны оештыручы тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана.

3.41. Беркетмәгә кул куелган көннән соңгы өч эш көне дәвамында электрон рәвештә уздырылган аукционны оештыручы әлеге аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәнең электрон мәйданчык операторына җибәрелүен тәэмин итә.

3.42. Аукционны оештыручыдан беркетмә алынган көннән башлап бер эш көне дәвамында электрон мәйданчык операторы электрон рәвештә уздырылган аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәнең электрон мәйданчыкта урнаштырылуын тәэмин итә.

3.43. Аукцион түбәндәге очракларда электрон рәвештә уздырылмый:

1) урманнарны авыл хуҗалыгын алып бару өчен файдалану максатларында дәүләт милкендә яки муниципаль милектә торучы урман кишәрлекләрен крестьян (фермер) хуҗалыкларына арендага тапшырганда;

2) Россия Федерациясе Урман кодексының 31 һәм 32 статьялары нигезендә урманнардан файдалану өчен дәүләт милкендә яки муниципаль милектә торучы урман кишәрлекләрен арендага тапшырганда.

Сатуларның нәтиҗәләре турында мәгълүматны аукционны оештыручы сатуларның рәсми сайтында урнаштыра.»;

III бүлекнең «Сатуларда җиңүче белән шартнамә төзү» һәм «Сатуларда бердәнбер катнашучы белән шартнамә төзү» бүлекчәләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сатуларда җиңүче белән шартнамә төзү

3.44. Сатуларда җиңүчене ачыклау процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

3.45. Министрлыкның аренда мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы процедураны үтәү өчен җаваплы зат булып тора.

3.46. Сатуларның рәсми сайтында сатулар турында мәгълүмат урнаштырылган көннән соң 10 көн узып киткәч 10 көн дәвамында яклар

урман кишәрлеген арендага алу шартнамәсенә кул куя һәм сатуларда җиңүче, алдан керткән түләү өлешен киметеп, аренда өчен түләү кертә.

3.47. Аукционда җиңүче урман кишәрлеген арендага алу турында шартнамә төзүдән баш тарткан очракта, тиешле шартнамә аннан алда аукцион предметы бәясе турында тәкъдим кертүче аукционда катнашучы белән төзелә.

3.48. Процедураның нәтиҗәсе булып урман кишәрлеген арендага алу шартнамәсен төзү тора.

Аукционда бердәнбер катнашучы (аукционда катнашу өчен бердәнбер гариза тапшырган гариза итүче) белән шартнамә төзү

3.49. Әлеге Административ регламентның 3.35 пунктының 2 һәм 3 пунктчаларында күрсәтелгән сәбәпләр буенча аукционны узмаган дип тану процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

3.50. Министрлыкның аренда мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы процедураны үтәү өчен җаваплы зат булып тора.

3.51. Аукционда катнашу өчен бердәнбер гариза тапшырган гариза бирүче яисә аукционда бердәнбер катнашучы аукцион уздырылган көннән соң 20 көннән соңга калмыйча, аукционны оештыручы белән урман кишәрлеген арендага алу шартнамәсен төзергә тиеш, аукционны оештыручы сатуларда бердәнбер катнашучы (аукционда катнашу өчен бердәнбер гариза тапшырган гариза итүче) белән тиешле шартнамәне төзүдән баш тартырга хокуклы түгел.

3.52. Процедураның нәтиҗәсе булып урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү тора.

3.53. Аукционда катнашу өчен бердәнбер гариза тапшырган гариза бирүче яисә аукционда бердәнбер катнашучы шартнамә төзүдән баш тарткан очракта аның алдан керткән түләү өлеше кире кайтарылмый.

Тиешле шартнамә төзүгә хокук аукцион предметы булып торган очракта шартнамә төзүдән баш тарткан затлар турында мәгълүмат намуссыз рәвештә урман кишәрлекләрен арендага алучылар һәм урман утыртмаларын сатып алучылар реестрына (алга таба – реестр) кертелә.

Россия Федерациясе Урман кодексының 79 статьясы 11 өлешендә күрсәтелгән вакыт тәмамланган көннән өч эш көне дәвамында Министрлык реестр алып баруга вәкаләтле федераль башкарма хакимияте органына реестрга кертү өчен шартнамә төзүдән баш тарткан затлар турында мәгълүмат җибәрә.

III бүлеккә түбәндәге эчтәлекле «Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү» бүлекчәсе өстәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү

3.54. Министрлыкка гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү турында ирекле рәвештә язылган гаризаның тапшырылуы (җибәрелүе) административ процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

3.55. Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган аренда мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы гариза бирүче тапшырган гаризаны карый һәм тиешле гаризаны теркәгән көннән башлап ике эш көненнән артык булмаган вакыт дәвамында гаризада күрсәтелгән белешмәләрне тикшерә.

3.56. Административ процедура буенча карар кабул итү критериесе булып хаталар һәм (яки) ялгышлар булуы яки булмавы тора.

3.57. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталар һәм (яки) ялгышлар булуы ачыкланган очракта, Министрлыкның аренда мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы тиешле гаризаны теркәгән көннән биш эш көненнән артык булмаган вакыт дәвамында күрсәтелгән документларның төзәтелүен һәм алмаштырылуын гамәлгә ашыра.

3.58. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталар һәм (яки) ялгышлар булмаган очракта, Министрлыкның аренда мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы гариза бирүчегә язмача рәвештә тиешле гаризаны теркәгән көннән биш эш көненнән артык булмаган вакыт дәвамында мондый хаталарның һәм (яки) ялгышларның булмавы турында хәбәр итә.

3.59. Гариза бирүчегә элек бирелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка алмашка төзәтелгәнен бирү (җибәрү) яки мондый хаталарның һәм (яки) ялгышларның булмавы турында хәбәр итү административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.»;

V бүлекнең атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе»;

5.2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү предметы булып Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләре (гамәл кылмавы) һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында алар тарафыннан кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) карарлар тора.»;

3 пунктчада «күрсәтелмәгән документларны тапшыруны» сүзләрен «аларның тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны»

сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 8-10 пунктчалары өстәргә:

«8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылу;

9) дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында туктатып тору нигезләре каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яисә документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә».»;

5.3 пунктта «вазыйфаи затка» сүзләреннән соң «, күпфункцияле үзәккә яки гавами-хокукый оештырылу рәвешендәге, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы булып торган тиешле дәүләт хакимияте органына тапшырылырга мөмкин.» сүзләрен өстәргә;

5.13 пунктның 1 пунктчасында «, шулай ук башка рәвешләрдәге» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5.23 – 5.25 пунктларын өстәргә:

«5.23. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Министрлык тарафыннан тормышка ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба гариза бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.24. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.25. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе түбәндәге норматив хокукый актлар нигезендә җайга салына:

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, федераль дәүләт хезмәткәрләренең, Россия Федерациясенең бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары вазыйфаи затларының, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча федераль законнар нигезендә вәкаләт бирелгән дәүләт корпорацияләренең һәм аларның вазыйфаи затларының, «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»

Федераль законның 16 статьясының 11 өлешендә каралган оешмаларның һәм аларның хезмәткәрләренең, шулай ук дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең һәм аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү һәм аларны карау тәртибе турында» 2012 елның 16 августындагы 840 номерлы карары.

Күрсәтелгән мәгълүмат Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) урнаштырыла.»;

1 нче кушымтада:

«шартнамә төзүгә хокукны сату буенча» сүзләрен «шартнамә төзүгә хокукка» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Аукционда җиңгән (аукционның бердәнбер катнашучысын аукционда катнашу өчен бердәнбер гариза тапшырган гариза бирүче дип таныган) очракта законнарда билгеләнгән срокларда урман кишәрлеген арендага алу шартнамәсе төзү йөкләмәсе кабул ителә.»;

2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен аукцион уздырмыйча арендага бирү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 26 декабрендәге ПУ-1277 номерлы Указында (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 15 гыйнварындагы ПУ-6 номерлы, 2016 елның 8 октябрендәге ПУ-911 номерлы һәм 2017 елның 27 июлендәге ПУ-660 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән):

а) атамасында «аукцион» сүзен «сатулар» сүзе белән алмаштырырга;

б) 1 пунктта «аукцион» сүзен «сатулар» сүзе белән алмаштырырга;

в) «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен аукцион уздырмыйча арендага бирү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

атамасында «аукцион» сүзен «сатулар» сүзенә алмаштырырга;

1.1 пунктта «аукцион уздырмыйча» сүзләрен «сатулар уздырмыйча» сүзләре белән алмаштырырга;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан күрсәтелә.

Министрлык, аның дәүләт хезмәтен күрсәтүче структур бүлекчәсе турында белешмә мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (http://minleshoz.tatarstan.ru/), «Дәүләт хезмәтләренең (функцияләренең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.gosuslugi.ru), Дәүләт

хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) урнаштырыла.»;

1.4, 1.5 һәм 1.6 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

2.1 пунктта «аукцион» сүзен «сатулар» сүзе белән алмаштырырга;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән мөнәсәбәтләр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (http://minleshoz.tatarstan.ru), «Дәүләт хезмәтләренең (функцияләренең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.gosuslugi.ru), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) урнаштырыла торган норматив хокукый актлар нигезендә җайга салына.»;

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Дәүләт хезмәтен алу буенча гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенә (алга таба – күпфункцияле үзәк), күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урынына шәхсән гариза иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлеп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);

почта юлламасы белән.»;

2.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Документлар бирү ысуллары әлеге Административ регламентның 2.6 пункты нигезендә билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.8 пункт өстәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү яисә 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 өлеше 4 пункты нигезендә билгеләнгән очраклардан кала, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларның булмавы һәм (яисә) аларда күрсәтелгән мәгълүматның дөрес булмавы беренче тапкыр документларны кабул итүдән баш тартуда күрсәтелмәгән документлар һәм белешмәләрне бирү.»;

2.10 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле 9 пунктчасы өстәргә:

«9) гариза бирүченең намуссыз рәвештә урман кишәрлекләрен арендага алучылар һәм урман утыртмаларын сатып алучылар реестрында булуы.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.»;

2.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.19. Гариза бирүче дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гариза белән күпфункцияле үзәккә гариза итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәктән дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза килгәндә, процедуралар әлеге Административ регламент нигезендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәктә күрсәтелми.»;

2.20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.20. Дәүләт хезмәте электрон рәвештә күрсәтелми.»;

3.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

III бүлектә түбәндәге эчтәлекле «Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү» бүлекчәсе өстәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү

3.45. Министрлыкка гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү турында ирекле рәвештә язылган гаризаның тапшырылуы (җибәрелүе) административ процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

3.46. Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган аренда мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы гариза бирүче тапшырган гаризаны карый һәм тиешле гаризаны теркәгән көннән башлап ике эш көненнән артык булмаган вакыт дәвамында гаризада күрсәтелгән белешмәләрне тикшерә.

3.47. Административ процедура буенча карар кабул итү критериесе булып хаталар һәм (яки) ялгышлар булуы яки булмавы тора.

3.48. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталар һәм (яки) ялгышлар булуы ачыкланган очракта, Министрлыкның аренда мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы тиешле гаризаны теркәгән көннән биш эш көненнән артык булмаган вакыт дәвамында күрсәтелгән документларның төзәтелүен һәм алмаштырылуын гамәлгә ашыра.

3.49. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталар һәм (яки) ялгышлар булмаган очракта, Министрлыкның аренда мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы гариза бирүчегә язмача рәвештә тиешле гаризаны теркәгән көннән биш эш көненнән артык булмаган вакыт дәвамында мондый хаталарның һәм (яки) ялгышларның булмавы турында хәбәр итә.

3.50. Гариза бирүчегә элек бирелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка алмашка төзәтелгәнен бирү (җибәрү) яки мондый хаталарның һәм (яки) ялгышларның булмавы турында хәбәр итү административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.»;

V бүлекнең атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш)

шикаять бирү тәртибе»;

5.2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү предметы булып Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләре (гамәл кылмавы) һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында алар тарафыннан кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) карарлар тора.»;

3 пунктчада «күрсәтелмәгән документларны тапшыруны» сүзләрен «аларның тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 8-10 пунктчалары өстәргә:

«8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылу;

9) дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында туктатып тору нигезләре каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яисә документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә».»;

5.3 пунктта «вазыйфаи затка» сүзләреннән соң «, күпфункцияле үзәккә яки гавами-хокукый оештырылу рәвешендәге, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы булып торган тиешле дәүләт хакимияте органына тапшырылырга мөмкин.» сүзләрен өстәргә;

5.13 пунктның 1 пунктчасында «, шулай ук башка рәвешләрдәге» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5.23 – 5.25 пунктларын өстәргә:

«5.23. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Министрлык тарафыннан тормышка ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат җибәрелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба гариза бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.24. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.25. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе түбәндәге норматив хокукый актлар нигезендә җайга салына:

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, федераль дәүләт хезмәткәрләренең, Россия Федерациясенең бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары вазыйфаи затларының, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча федераль законнар нигезендә вәкаләт бирелгән дәүләт корпорацияләренең һәм аларның вазыйфаи затларының, «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясының 11 өлешендә каралган оешмаларның һәм аларның хезмәткәрләренең, шулай ук дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең һәм аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү һәм аларны карау тәртибе турында» 2012 елның 16 августындагы 840 номерлы карары.

Күрсәтелгән мәгълүмат Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) урнаштырыла.»;

1 нче кушымтада раслау грифында «аукцион» сүзен «сатулар» сүзенә алмаштырырга;

$1^1$ нче кушымтада:

раслау грифында «аукцион» сүзен «сатулар» сүзенә алмаштырырга;

персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалыкта «аукцион» сүзен «сатулар» сүзенә алмаштырырга;

2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре төзү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1191 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 8 октябрендәге ПУ-911 номерлы, 2017 елның 27 июлендәге ПУ-660 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Гражданнарның шәхси ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләрен төзү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан күрсәтелә.

Министрлык, аның дәүләт хезмәтен күрсәтүче структур бүлекчәсе турында белешмә мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (http://minleshoz.tatarstan.ru/), «Дәүләт хезмәтләренең (функцияләренең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.gosuslugi.ru), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) урнаштырыла.»;

1.4 пунктны һәм 1.5 пунктның 1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.6 пунктта «Бүлекнең» сүзен «Министрлыкның дәүләт урман реестры, урманнардан файдалану һәм урман корылышы бүлегенең» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән мөнәсәбәтләр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (http://minleshoz.tatarstan.ru), «Дәүләт хезмәтләренең (функцияләренең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.gosuslugi.ru), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) урнаштырыла торган норматив хокукый актлар нигезендә җайга салына.»;

2.6 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Дәүләт хезмәтен алу буенча гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенә (алга таба – күпфункцияле үзәк), күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урынына шәхсән гариза иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);

почта юлламасы белән.»;

2.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү яисә 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 өлеше 4 пункты нигезендә билгеләнгән очраклардан кала, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларның булмавы һәм (яисә) аларда күрсәтелгән мәгълүматның дөрес булмавы беренче тапкыр документларны кабул итүдән баш тартуда күрсәтелмәгән документлар һәм белешмәләрне бирү.»;

2.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.19. Гариза бирүче дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гариза белән күпфункцияле үзәккә гариза итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәктән дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза килгәндә, процедуралар әлеге Административ регламент нигезендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәктә күрсәтелми.»;

3.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

III бүлекнең «Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү

3.30. Министрлыкка гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү турында ирекле рәвештә язылган гаризаның тапшырылуы (җибәрелүе) административ процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

3.31. Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган аренда мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы гариза бирүче тапшырган гаризаны карый һәм тиешле гаризаны теркәгән көннән башлап ике эш көненнән артык булмаган вакыт дәвамында гаризада күрсәтелгән белешмәләрне тикшерә.

3.32. Административ процедура буенча карар кабул итү критериесе булып хаталар һәм (яки) ялгышлар булуы яки булмавы тора.

3.33. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталар һәм (яки) ялгышлар булуы ачыкланган очракта, Министрлыкның аренда мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы тиешле гаризаны теркәгән көннән биш эш көненнән артык булмаган вакыт дәвамында күрсәтелгән документларның төзәтелүен һәм алмаштырылуын гамәлгә ашыра.

3.34. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталар һәм (яки) ялгышлар булмаган очракта, Министрлыкның аренда мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы гариза бирүчегә язмача рәвештә тиешле гаризаны теркәгән көннән биш эш көненнән артык булмаган вакыт дәвамында мондый хаталарның һәм (яки) ялгышларның булмавы турында хәбәр итә.

3.35. Гариза бирүчегә элек бирелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка алмашка төзәтелгәнен бирү (җибәрү) яки мондый хаталарның һәм (яки) ялгышларның булмавы турында хәбәр итү административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.»;

V бүлекнең атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе»;

5.2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү предметы булып Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләре (гамәл

кылмавы) һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында алар тарафыннан кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) карарлар тора.»;

3 пунктчада «күрсәтелмәгән документларны тапшыруны» сүзләрен «аларның тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 8-10 пунктчалары өстәргә:

«8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылу;

9) дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында туктатып тору нигезләре каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яисә документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә».»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Шикаять Министрлыкка, шулай ук югары органга яисә югары вазыйфаи затка, күпфункцияле үзәккә яки гавами-хокукый оештырылу рәвешендәге, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы булып торган тиешле дәүләт хакимияте органына тапшырылырга мөмкин.»;

5.13 пунктның 1 пунктчасында «, шулай ук башка рәвешләрдәге» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5.23 – 5.25 пунктларын өстәргә:

«5.23. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Министрлык тарафыннан тормышка ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат җибәрелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба гариза бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.24. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.25. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе түбәндәге норматив хокукый актлар нигезендә җайга салына:

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият

органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, федераль дәүләт хезмәткәрләренең, Россия Федерациясенең бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары вазыйфаи затларының, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча федераль законнар нигезендә вәкаләт бирелгән дәүләт корпорацияләренең һәм аларның вазыйфаи затларының, «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясының 11 өлешендә каралган оешмаларның һәм аларның хезмәткәрләренең, шулай ук дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең һәм аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү һәм аларны карау тәртибе турында» 2012 елның 16 августындагы 840 номерлы карары.

Күрсәтелгән мәгълүмат Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) урнаштырыла.»;

2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

___________